| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан Исполнительный комитет Чумарлинского сельского поселения Сармановского муниципального района** | **Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2025 ел, 7 август** **№ 13**

Чукмарлы авыл җирлеге Башкарма комитетының 05.04.2023 ел, № 4 «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашкан урыны турында мәгълүмат бирү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең "Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турындагы нигезләмәне раслау хакында" 14.03.2024 No 300 карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Чукмарлы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашкан урыны турында мәгълүмат бирү турында» 05.04.2023 ел, № 4 карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

Карарның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Кулланучыларга терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында мәгълүмат бирү әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Чукмарлы авыл җирлеге
башкарма комитет җитәкчесе И.Х.Хадиуллин